## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Рус Шуган торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 8 декабре** **№ 5**

Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Рус Шуган авылы биләмәсендә гражданнар җыенының 2025 елның 30 октябрендәге 1 номерлы карарында хокукый норманы дөрес кулланмау сәбәпле, гражданнар җыенының 2025 елның 8 декаберендә узган җыен нәтиҗәләре белән беркетмәсе төзелде: «Гражданнар җыенының 2025 елның 30 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә ризамы Сез», карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә»» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә»» сүзләренә алмаштырырга.

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 273 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 163 кеше кертелде, бу 59% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 159 катнашучысы тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 5 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **карар бирде**:

1. Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Рус Шуган авылы биләмәсендә гражданнар җыенының 2025 елның 30 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, гражданнар җыены карары преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә»» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә»» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында»: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://muslumovo.tatarstan.ru, гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Рус Шуган авылында, Ленин урамында, 18 нче А йорт янында мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Шуган авыл җирлеге башлыгы** **А.Ю. Басорина**

СОВЕТ ШУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1629001184 КПП 162901001 ОГРН 1021605558413